| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

23.06.2020 ел　　　Баулы шәһәре　　　№135

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы территориясендә
табигый һәм техноген характердагы
гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация
чараларын планлаштыру һәм уздыру
эшен оештыру турындагы
нигезләмәне раслау хакында

“Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау турында” 2018 елның 5 февралендәге 58 номерлы карары нигезендә, эвакуация чараларын һәм гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация органнары эшчәнлеген камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм уздыру эшен оештыру турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырырга: http://www.bavly.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы

башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.Р. Вәлиевка йөкләргә.

Җитәкче                                                                                И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның
23 июнендәге 135 номерлы
карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм уздыру эшен оештыру турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм уздыру эшен оештыруны билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

халыкны эвакуацияләү - гадәттән тыш хәл зоналарыннан яисә гадәттән тыш хәл чыгу ихтималы булган зоналардан халыкны оешкан төстә чыгару, алып китү, шулай ук районда эвакуацияләнгәннәрнең тормышын тәэмин итү чаралары комплексы;

халыкның беренче чираттагы яшәешен тәэмин итү - гадәттән тыш хәлләр зонасында халыкның беренче чираттагы ихтыяҗларын вакытында канәгатьләндерү;

куркынычсыз район - Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының административ чиге чикләрендә, мөмкин булган хәвеф-хәтәр зоналарыннан, мөмкин булган җимерелүләр зоналарыннан тыш һәм җирле һәм эвакуацияләнә торган халыкны яшәтү өчен әзерләнгән, шулай ук матди һәм мәдәни кыйммәтләрне урнаштыру һәм саклау өчен территория;

халыкны реэвакуацияләү - вакытлыча урнаштыру зоналарыннан халыкны даими яшәү районнарына оешкан төстә алып китү чаралары комплексы.

2. Эвакуация чараларын планлаштыру нигезләре

2.1. Халыкны эвакуацияләүне планлаштыру, оештыру һәм уздыру түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, Баулы муниципаль районының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе;

- табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны яшәү өчен вакытлыча урнаштыру пунктлары;

- табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны урнаштыру өчен озак яшәү пунктларында;

- эвакуацияләнә торган халыкны чыгару буенча оператив төркемнәр (алга таба - эвакуация органнары).

Бөтен эвакуация органнары Баулы муниципаль районы гражданнар оборонасы җитәкчесе - Баулы муниципаль районы башлыгына буйсыналар.

2.2. Табигый һәм техноген характердагы фаразлана торган һәм (яисә) килеп чыккан гадәттән тыш хәлгә бәйле рәвештә эвакуация органнары эшчәнлеге түбәндәге режимнарда гамәлгә ашырыла:

- көндәлек эшчәнлек режимында - гадәттән тыш хәл барлыкка килү куркынычы булмаганда;

- гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы булганда - югары әзерлек режимында;

- гадәттән тыш хәл режимында - гадәттән тыш хәл килеп чыккан һәм бетерелгән очракта.

Баулы муниципаль районы территориясендә эвакуация органнары эшчәнлегенең тиешле режимын кертү турындагы карарны, конкрет шартларны исәпкә алып, Баулы муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе кабул итә.

Эвакуация органнарының эш режимнарына бәйле рәвештә, төп чаралар түбәндәгеләр:

а) көндәлек эшчәнлек режимында:

гадәттән тыш хәлләр килеп туганда, халыкны эвакуацияләү өчен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча Баулы муниципаль районының эш план бүлекләрен эшләү;

табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл зонасында яшәүче халыкны исәпкә алу;

Баулы муниципаль районы территориясендә халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын исәпкә алу;

эвакуация маршрутларын билгеләү;

гадәттән тыш хәлләр килеп туганда, эвакуацияләнә торган халыкны беренче чиратта кирәкле әйберләр белән тәэмин итү мәсьәләләрен планлаштыру һәм хәл итү;

гадәттән тыш хәлләр килеп туганда халыкны эвакуацияләүне транспорт белән тәэмин итү мәсьәләләрен исәпкә алу, планлаштыру һәм төгәлләштерү;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссияләрне эвакуация чараларын уздыруга әзерләү;

халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары администрацияләрен өйрәтү;

халык һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә белемнәрне тарату;

б) югары әзерлек режимында:

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләрен, вакытлыча урнаштыру пунктлары администрацияләрен, озак яшәү пунктларын әзерлеккә китерү;

эвакуацияләнергә тиешле халык санын төгәлләштерү; куркынычсыз районнарда эвакуацияләнә торган халыкны кабул итү, урнаштыру һәм беренче чиратта кирәкле әйберләр белән тәэмин итү планнарын төгәлләштерү;

эвакуация өчен кулланыла торган транспорт чараларын бүлү; эвакуация маршрутларын әзерләү, юл билгеләре һәм күрсәткечләр кую;

вакытлыча урнаштыру пунктларын, озак яшәү пунктларын җәелдерүгә әзерләнү;

хәбәр итү һәм элемтә системаларының әзерлеген тикшерү;

в) гадәттән тыш хәл режимында:

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе әгъзаларының тәүлек буе кизү торуын оештыру;

халыкка хәбәр итүнең барышын һәм утырту пунктларына транспорт бирүне тикшереп тору буенча Баулы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары, вакытлыча урнаштыру пунктлары администрацияләре, озак яшәү пунктлары, Баулы муниципаль районының транспорт хезмәте белән хезмәттәшлек;

эвакуацияләнә торган халыкны җыю һәм аны имин районнарга вакытлыча урнаштыру пунктлары, озак яшәү пунктларына җибәрү буенча эвакуация органнарының эше белән җитәкчелек итү;

халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын, озак яшәү пунктларын үз вакытында җәелдерүне тикшереп тору;

вакытлыча урнаштыру пунктлары, озак яшәү пунктлары администрацияләре эшен координацияләү;

халыкны эвакуацияләү барышы турында мәгълүматлар җыю һәм гомумиләштерү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиягә доклад ясау;

Баулы муниципаль районы территориясендә халыкны беренче чиратта кирәкле әйберләр белән тәэмин итүне һәм яклауны оештыру.

## 3. Эвакуацион чаралар үткәрү

3.1. Гадәттән тыш хәл зонасыннан халыкны эвакуацияләү гадәттән тыш хәл килеп чыгу һәм үсеш шартларыннан, гадәттән тыш хәл чыганагының зарарлый торган факторлары йогынтысының характерыннан чыгып башкарыла.

Гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу төрендә төгәл фараз булганда әзерлек чаралары оештырыла һәм уздырыла, аларның максаты халыкны гадәттән тыш

хәл зонасыннан оешкан төстә алып китү яисә чыгару өчен уңай шартлар тудырудан гыйбарәт.

3.2. Әзерләү чаралары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

барлык дәрәҗәдәге эвакуация органнарын әзерлеккә китерү һәм аларның эш тәртибен төгәлләштерү, җәяү һәм транспорт белән эвакуацияләнергә тиешле халык санын һәм категориясен төгәлләштерү;

транспорт чараларын бүлү;

эвакуация маршрутларын әзерләү, юл билгеләре һәм күрсәткечләр урнаштыру;

халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын җәелдерүгә әзерлек;

хәбәр итү һәм элемтә системаларының әзерлеген тикшерү.

эвакуация игълан иткәндә халыкка эш итү тәртибен җиткерү.

3.3. Халыкны эвакуацияләү үткәрүгә сигнал алганнан соң түбәндәге чаралар башкарыла:

эвакуация чараларының идарә органнарына, Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисенә һәм территориядә урнашкан оешмалар җитәкчеләренә, шулай ук халыкка эвакуация уздыруның башлануы һәм тәртибе турында хәбәр итү;

вакытлыча урнаштыру пунктларын, озак яшәү пунктларын җәелдерү һәм аларны әзерлеккә китерү;

эвакуацияләнергә тиешле халыкны җыю һәм имин районнарга җибәрү өчен әзерләү;

җәяүле колонналар маршрутларында башлангыч пунктлар булдыру һәм аларга чыгу, транспорт чараларын утырту пунктларына бирү, эвакуацияләнә торган халыкны транспортка утырту һәм эвакуация маршруты буенча хәрәкәт итү;

эвакуацияләнә торган халыкны куркынычсыз районнарда (вакытлыча урнаштыру һәм озак яшәү пунктларында) кабул итү һәм урнаштыру.

4. Эвакуация чараларын тәэмин итү

4.1. Эвакуацияне оешкан төстә үткәрү өчен шартлар тудыру максатыннан, транспорт, медицина, җәмәгать тәртибен саклауның, юл хәрәкәте иминлегенең, инженерлык, матди-техник, разведка, элемтә һәм хәбәр итүнең түбәндәге төрләре буенча чаралар планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла.

4.2. Техноген аварияләр һәм табигый бәла-казалар зоналарыннан халыкны эвакуацияләүне транспорт белән тәэмин итү үз эченә эвакуацияләү өчен билгеләнгән транспорт чараларын әзерләүне, бүлүне һәм эксплуатацияләүне ала.

Халыкны эвакуацияләү транспорт чараларының җитәрлек паркы булуны, аларны (шул исәптән шәхси файдаланудагы транспортны да) эвакочараларга җәлеп итү мөмкинлекләрен, транспорт коммуникацияләреннән максималь файдалануны таләп итә.

Халыкны эвакуацияләү барышында җәмәгать транспорты эше аны файдалануның төрле вариантларын күздә тота:

халыкны яшәү урыныннан вакытлыча урнаштыру пунктларына кадәр илтеп җиткерү;

эвакуацияләнә торган халыкны гадәттән тыш хәл зонасыннан куркынычсыз районнарга чыгару.

Автотранспортта ташуны оешкан төстә гамәлгә ашыру һәм эвакуациянең барлык этапларында алар белән тотрыклы идарә итү шартлары тудыру өчен махсус автомобиль формированиеләре төзелә, атап әйткәндә:

автомобиль колонналары, гражданнарның шәхси файдалануындагы җәмәгать транспорты һәм транспорт төркемнәре.

Автомобиль колонналары гомуми файдаланудагы автотранспорт предприятиесе һәм икътисадның башка тармакларындагы оешмалар, шулай ук гражданнарның шәхси транспортының базасында формалаша.

4.3. Эвакуацияне медицина-санитария белән тәэмин итү эвакуацияләнә торган халыкның сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән оештыру, дәвалау, санитария-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар уздыруны,

эвакуация барышында авырган һәм имгәнүләр алган гадәттән тыш хәлләрдән зыян күрүчеләргә вакытында медицина ярдәме күрсәтүне, шулай ук йогышлы авыруларның килеп чыгуын һәм таралуын кисәтүне үз эченә ала.

Эвакуацияне әзерләгәндә һәм үткәргәндә түбәндәге чаралар башкарыла:

вакытлыча урнаштыру урыннарында (халыкны вакытлыча урнаштыру һәм озак яшәү пунктларында), утырту (төшерү) пунктларында һәм юлда медицина пунктлары җәелдерү, шулай ук эвакуацияләнә торган халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина персоналы кизү торуын оештыру;

йөри алмый торган авыруларга хезмәт күрсәтүне оештыру;

эвакуацияләнә торган халыкны вакытлыча урнаштыру урыннарының санитар торышын, халыкның гарантияләнгән куркынычсыз эчә торган су белән тәэмин ителешен, су белән тәэмин итү чыганакларының торышын тикшереп торуны тәэмин итү;

эпидемиологик хәлне өзлексез күзәтү, йогышлы авыруларны ачыклау һәм эпидемиягә каршы башка чараларны үтәү;

халыкны реэвакуацияләгәндә техноген аварияләр, һәлакәтләр һәм стихияле бәла-казалар белән бәйле гадәттән тыш хәлләр зоналарын дезинфекцион һәм башка чаралар, яшәү тирәлеген лаборатор тикшеренүләр үткәреп тулысынча санитар-эпидемиологик тикшерү үткәрү;

эвакуацияләнә торган халыкка хезмәт күрсәтүгә җәлеп ителә торган медицина пунктларын, медицина оешмаларын һәм сәламәтлек саклау оешмаларын тәэмин итү.

4.4. Эвакуация чараларын үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклау һәм юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү түбәндәге чараларны үз эченә ала:

эвакуация, коткару һәм башка кичектергесез чаралар үткәрүдә мәшгуль булмаган гражданнарның транспортта һәм җәяү узуын чикләүне күздә тоткан үткәрү режимы (автомобиль юлларын һәм җәяүлеләр юлларын ябу) гамәлгә ашыру;

эвакуацион ташулар өчен билгеләнгән транспорт чараларының техник торышын тикшерү;

халыкны гадәттән тыш хәл зоналарыннан тиз арада чыгаруны тәэмин итү максатларында транзит транспортын мобилизацияләү өчен җаваплы вазыйфаи затларга (кирәк булганда) ярдәм күрсәтү;

эвакуация объектларында (вакытлыча урнаштыру пунктларында, озак яшәү пунктларында, утырту һәм төшерү пунктларында һ. б.), эвакуация маршрутларында, торак пунктларда һәм эвакуацияләнгән халык урнашу урыннарында тәртип саклау һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү, паника һәм дөрес булмаган мәгълүмат таралуны булдырмау;

объектларны билгеләнгән тәртиптә саклау;

шәһәр эчендәге һәм шәһәр читендәге эвакуация маршрутларында юл хәрәкәтен җайга салу;

эвакуацияләнүче халык белән автоколонналарны имин районнарга озату;

автомобиль юллары буенча пассажирлар йөртүнең билгеләнгән чиратын һәм гадәттән тыш хәл зонасына транспорт кертү режимын тәэмин итү;

торак пунктларда, эвакуация маршрутларында һәм халык урнашкан урыннарда җинаятьчелек, мародерлык белән көрәш.

4.5. Эвакуация чараларын үткәргәндә инженерлык ягыннан тәэмин итү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

юлларның торышын яхшырту, күперләрне көчәйтү, җимерелгән яисә үтеп йөри алмаслык юлларны әйләнеп узу юлларын җиһазлау;

кышын эвакуацияләгәндә юлларны кардан чистарту;

эвакуация вакытында юлның авыр уза торган участокларын карау, биеклекккә менү һәм авыр үтелә торган участокларны үтү өчен тягачлар бүлеп бирүне;

су белән тәэмин итү чыганакларын яклау;

Җәмәгать биналарын, эвакуацияләнүчеләрне урнаштыру корылмаларын җиһазлау.

4.6. Эвакуация чараларын үткәргәндә матди-техник тәэмин итү транспорт чараларына техник хезмәт күрсәтүне һәм ремонтлауны оештыруны, ягулык-

майлау материаллары һәм запас частьләр, су, азык-төлек һәм кирәк-яраклар белән тәэмин итүне, кирәкле мөлкәт белән тәэмин итүне үз эченә ала.

4.7. Эвакуация чараларын үткәргәндә элемтә һәм хәбәр итүне тәэмин итү вакытлы урнаштыру пунктларын, озак яшәү пунктларын, эвакуация чаралары белән идарә органнарын стационар яки күчмә элемтә чаралары белән җиһазлауны, шулай ук каналларның, элемтә чараларының һәм телерадиотапшырулар челтәрләренең эвакуациянең барлык этапларында хәбәр итү системаларында кулланыла торган техник әзерлеген тәэмин итүне үз эченә ала.

5. Эвакуацион чараларны финанслау

Эвакуация чараларын финанслау Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының эшләр
белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов